**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы, М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

РЕШЕНИЕ КАРАР

02 ноябрь 2023 ел №21

«Җир салымы турында» Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының 2020 елның 26 февраленда 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 113 пункты, Сарман муниципаль районының «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман авыл җирлеге карар итте:

1. «Җир салымы турында» Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының 2020 елның 26 февралендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.2.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2.1 торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге рәисе Ф.М.Хөснуллин